СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

17.11.2023 с. Печищи № 37-194

Торак пункт территориясенең шушы өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен Югары Ослан муниципаль районы  Печищи авыл җирлеге Печищи авылы торак пункты территориясенең бер өлеше чикләрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Печищи авыл җирлеге Уставының 24 статьясына ярашлы,

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге  Советы
карар итте:

1. Гражданнарның яшәвенең түбәндәге территорияләре чикләрендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыру өчен территориянең бер өлеше чикләрен билгеләргә:

Печищи авылы:

Исаев урамында 5-9 нчы номерлы торак йортлар.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Печищи авыл җирлеге башлыгы Е.В. Рахматулина